ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2019 ел № 977

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Автомобиль юллары турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә юллар эшчәнлеге хакында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законы, шәһәр Уставы, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары аша уза торган маршрутлар буенча автомобильләрдә авыр йөкләр, эре габаритлы

йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 4543 нче карары;

2) 2016 елның 26 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 80 нче санында басылып чыккан, 2016 елның 1 августында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары аша уза торган маршрутлар буенча автомобильләрдә авыр йөкләр, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 30 июнендәге 3379 нчы карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 25 февралендәге
977 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасының маршруты, маршрут өлеше Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары аша үткән һәм федераль, региональ яки муниципальара әһәмияттәге юллар, андый автомобиль юллары участоклары аша үтмәгән очракта, авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: транспорт чаралары хуҗалары – физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне үтәүче – Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (алга таба – Идарә).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Идарәнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 423 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр;
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Идарәнең белешмә телефоннары: 8 (8552) 30-55-57, 30-59-52.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтының адресы – www.nabchelny.ru (алга

таба – шәһәрнең рәсми сайты).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/) аша;

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша;

5) Башкарма комитетта (Идарәдә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон рәвештә E-mail: kancel.chelny@tatar.ru, Ik414@mail.ru.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Идарә белгече тарафыннан шәһәрнең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

«Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 257-ФЗ санлы Федераль закон (РФ Законнар җыентыгы, 12.11.2007, № 46, ст. 5553);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 45-ЗРТ санлы ТР Законы (Татарстан Республикасы, 03.08.2004, № 155-156,);

Татарстан Республикасының «Автомобиль юллары турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә юллар эшчәнлеге хакында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законы, (Татарстан Республикасы, 11.08.2009, №160);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе автомобиль юлларында авыр йөк ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китергән зыянны каплау турында» 2009 елның 16 ноябрендәге 934 нче карары («РФ Законнар җыентыгы», 23.11.2009, № 47, ст. 5673);

Россия Транспорт министрлыгының 2012 елның 24 июлендәге 258 нче приказы белән расланган автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү тәртибе (Российская газета, 16.11.2012, №265) (алга таба – Рөхсәт бирү тәртибе);

Россия Транспорт министрлыгының 2018 елның 12 гыйнварындагы 10 нчы приказы белән расланган Автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтен оештыруга таләпләр (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.04.2018);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) («Челнинские известия», 10.12.2005, № 235-237, «Челнинские известия», 30.12.2005, № 249-250);

«Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү турында» 2011 елның 14 апрелендәге 1882 нче карары («Челнинские известия», 20.04.2011, № 55);

Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре;

Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш регламенты;

Башкарма комитетның 2017 елның 11 июлендәге 674-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халыкның яшәешен тәэмин итү идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Идарә турында нигезнамә).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

йөк урыны – ташу өчен кабул итеп алынган материаль объект;

бүленә торган йөк – куллану үзлекләрен югалтмыйча һәм бозылу куркынычы булмаган, 2 яки күбрәк йөк урынына урнаштырыла ала торган йөк;

гариза – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос;

эре габаритлы транспорт чарасы – йөк белән яки йөксез килеш габаритлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, рөхсәт ителгән габаритлардан артып киткән транспорт чарасы;

бүленми торган йөк – куллану үзлекләрен югалтмыйча һәм бозылу куркынычы булмаган, ике яки күбрәк өлешкә бүленә алмый торган йөк. Эре габаритлы транспорт чарасы белән ташыганда бүленми торган йөк дип габариты (габаритлары) буенча бүленми торган дип исәпләнгән, транспорт чарасына андый йөк ташыганда рөхсәт ителә торган габаритлардан артып киткән йөк санала;

йөк ташучы – эре габаритлы һәм (яки) авыр йөк ташуны гамәлгә ашыручы юридик яки физик зат;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе-документына кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

авыр йөк ташучы транспорт чарасы – йөк белән яки йөксез килеш һәм (яки) күчәргә төшкән авырлык массасы транспорт чарасына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, рөхсәт ителгән массадан һәм (яки) күчәргә төшкән, рөхсәт ителгән авырлыктан артып киткән массалы транспорт чарасы.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Яр Чаллы шәһәренең жирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү | Муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Идарә йөзендә Башкарма комитет | 257-ФЗ санлы Федераль законның 31 маддәсендәге 10 бүлекнең 6 пункты;<br>Рөхсәт бирү тәртибе; шәһәр Уставының 41 маддәсе; |

| | | |
|---|---|---|
| | | Идарә турында нигезнамә; |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | 257-ФЗ санлы Федераль законның 31 маддәсе;<br>Рөхсәт бирү тәртибенең 3, 40 пунктлары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы | 1) гариза теркәлгән көннән башлап 11 эш көнендә;<br>2) транспорт чарасы маршрутын Дәүләт автоинспекциясе белән килешенү кирәк булган очракта, гариза теркәлгән датадан башлап 15 эш көне эчендә;<br>3) гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен җибәрелгән транспорт чараларын, шулай ук телевизион компанияләрнең (төп һәм ярдәмче транспорт чараларыннан (ПТС) торган, йөкләре видеога төшерүләр өчен кирәкле җиһазлардан торган күчмә телевизион станцияләр, һәм видеолар һәм трансляцияләр төшерү өчен җибәрелгән мобиль энергетик комплекслардан (МЭК) торган эре габаритлы һәм (яки) авыр йөк ташучы махсуслаштырылган транспорт чараларын экстрен үткәрү буенча гариза кергән очракта, бер эш көне эчендә;<br>4) авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыру өчен автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту яки автомобиль юлларын, аларның | Рөхсәт бирү тәртибенең 41, 43 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | участокларын, шулай ук автомобиль юлы белән кисешкән корылмалар һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителгән очракта, махсус рөхсәт бирү срогы күрсәтелгән чараларны үткәрү срогына кадәр арттырыла;<br>5) факсимиль элемтәне, Порталны һәм (яки) бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын куллану мөмкинлеге булмаган очракта, махсус рөхсәт бирү срогы Россия Почтасы документларны китереп житкерү срогына кадәр арттырыла. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча гариза;<br>2) шәхесне таныклаучы документның күчермәсе;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтен раслаучы документның күчермәсе (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>4) авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуда файдалану планлаштырылган транспорт чарасы документларының (транспорт чарасының паспорты яки транспорт чарасын теркәү турында таныклыгы) күчермәсе;<br>5) авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуда файдалану планлаштырылган транспорт чарасының (автопоездның) Рөхсәт бирү тәртибендә каралган андый йөкләр урнаштыруның сурәте | Рөхсәт бирү тәртибенең 6, 9, 10 пунктлары; |

| | | |
|---|---|---|
| | булган схемасы. Транспорт чарасы схемасында йөк ташуда катнашучы транспорт чарасы, андагы күчәрләр һәм тәгәрмәчләр саны, күчәрләр һәм тәгәрмәчләрнең үзара урнашуы күчәрләргә төшкән авырлыкны бүлү һәм авырлык күчәр озынлыгы буенча тигез итеп бүленмәгән очракта – аерым тәгәрмәчләргә бүлү тасвирлана;<br>6) транспортта ташыла торган йөкне ташуга техник таләпләр турында мәгълүматлар;<br>7) махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслаган түләү документы күчермәсе;<br>8) авыр йөк ташучы транспорт чарасының хуҗасы тарафыннан андый транспорт чарасы китергән зыянны каплавын раслаган документ;<br>9) автомобиль юлларын ныгыту яки автомобиль юлларын яки аларның участокларын төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү чыгымнарын түләүне раслаган түләү документы күчермәсе (ныгыту һәм махсус чаралар күрү кирәк булган очракта).<br>Гариза һәм транспорт чарасының (автопоездның) схемасы гариза бирүченең имзасы (физик затлар өчен), җитәкче яки вәкаләтле затның имзасы һәм мөһере (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен) белән раслана.<br>Әлеге пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документларның күчермәләре транспорт чарасы хуҗасының имзасы һәм мөһере белән яки нотариаль раслана. | Рөхсәт бирү тәртибенең 9 пунктының 4 пунктчасы;<br>257-ФЗ санлы Федераль законның 31 маддәсендәге 6 бүлекнең 2 пункты;<br>Рөхсәт бирү тәртибенең 37 пункты<br>Рөхсәт бирү тәртибенең 10 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар;<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар. | Рөхсәт бирү тәртибенең 7 абзацындагы 9 пункт |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган һәм, норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү таләп ителә торган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Идарә (шәһәрнең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлы хуҗасы буларак маршрутны килешенә);<br>2) РФ ЭЭМ ЮХИДИ территориаль идарәсе;<br>3) РФ транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең территориаль бүлекчәсе;<br>4) шәһәрнең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлы белән кисешкән корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләре хуҗалары (авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыру өчен автомобиль юлы белән кисешкән корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү өчен махсус чаралар күрү таләп ителмәгән очракта);<br>5) тимер юл транспорты инфраструктурасы хуҗалары (авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасының маршруты тимер юл киселешләре аша узган очракта).<br>Әлеге пунктның 2, 3 | 257-ФЗ санлы Федераль законның 31 маддәсендәге 7 бүлек;<br>Рөхсәт бирү тәртибенең 16, 23, 24 пунктлары;<br><br>РФ Президентының 1998 елның 15 июнендәге 711 нче указы белән расланган Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе турында нигезнамә;<br><br>РФ Хөкүмәтенең 2004 елның 30 июлендәге 398 нче карары белән расланган Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт турында нигезнамә |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктчаларында күрсәтелгән органнар белән килешенү түбәндәге очракларда кирәк:<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, рөхсәт ителгән габаритларны 2 проценттан да күбрәк арттыру;<br>- әгәр авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташучы транспорт чарасы хәрәкәте өчен автомобиль юлларының аерым участокларын ныгыту яки автомобиль юлларын һәм алар белән кисешкән корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен килешенгән маршрут чикләрендә төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү таләп ителсә. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Гаризаның вәкаләте булмаган зат тарафыннан имзаланган булуы;<br>2) гаризада Рөхсәт бирү тәртибенең 8 пунктында билгеләнгән мәгълүматларның булмавы;<br>3) гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның теркәлмәве | Рөхсәт бирү тәртибенең 12 пункты |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Рөхсәт бирү тәртибе нигезендә Башкарма комитетның тиешле маршрут буенча махсус рөхсәтләр бирергә хокукы булмаган очракта; | Рөхсәт бирү тәртибенең 22, 40 пунктлары,<br>карар үз көченә кергән көннән башлап,<br>РФ Югары Судының 2017 елның 16 гыйнварындагы АКПИ16-1161 карары белән 22 пункт гамәлдән |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) гаризада һәм документларда күрсәтелгән мәгълүматлар транспорт чарасының һәм йөкнең характеристикасына, шулай ук тиешле авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләрне ташуны гамәлгә ашыруның техник мөмкинлегенә туры килмәү;<br>3) бүленә торган йөкне ташу турында билгеләнгән таләпләр үтәлмәү;<br>4) маршрутны килешенгәндә, автомобиль юлларының, ясалма корылмаларның яки инженерлык коммуникацияләренең техник торышына бәйле рәвештә, шулай ук юл хәрәкәте иминлеге таләпләре буенча күрсәтелгән техник характеристикалар белән транспорт чарасының тиешле маршрут буенча йөк ташуны гамәлгә ашыра алмавы билгеләнү;<br>5) гариза бирүченең түбәндәгеләргә рөхсәте булмау:<br>- Рөхсәт бирү тәртибенең 26 пунктында каралганча автомобиль юлының техник торышын бәяләү;<br>- законнарда билгеләнгән очракларда, автомобиль юлының техник торышын бәяләү нигезендә билгеләнгән автомобиль юлы белән кисешкән корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү өчен махсус чаралар күрү;<br>законнарда билгеләнгән очракларда, автомобиль юлларын ныгыту яки автомобиль юлының техник торышын бәяләү нигезендә | чыккан дип танылган |

| | | |
|---|---|---|
| | билгеләнгән автомобиль юлларын яки участокларын төзекләндерү өчен махсус чаралар күрү;<br>6) автомобиль юлларының техник торышын, аларны ныгытуны бәяләү гариза бирүче белән килешенү буенча башкарылган очракта, гариза бирүче андый эшләр өчен түләмәгән булу;<br>7) автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлы белән кисешкән корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү гариза бирүче белән килешенү буенча башкарылган очракта, гариза бирүче андый эшләр өчен түләмәгән булу;<br>8) гариза бирүченең авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы автомобиль юлларына китергән зыянны каплау чыгымнарын түләмәгән булуы;<br>9) махсус рөхсәт биргән вакытта гаризаның һәм автопоезд схемасының төп нөсхәсе, транспорт чарасының расланган теркәлү документлары булмау, әгәр гариза һәм документлар вәкаләтле органга җибәрелгән булса. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы һәм башка түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | 1) Дәүләт пошлинасының күләме – 1600 сум;<br>2) авыр йөк ташучы транспорт чарасы тарафыннан китерелгән зыянны каплау чыгымнарын түләү күләме Башкарма комитетның | РФ Салым кодексының 333.33 маддәсендәге 1 пунктның 111 пунктчасы;<br>257-ФЗ санлы Федераль законның |

| | | |
|---|---|---|
| | «Яр Чаллы шәһәренең жирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү турында» 2011 елның 14 апрелендәге 1882 нче карары нигезендә билгеләнә. | 31 маддәсенең 13 бүлеге |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалануга гариза бирү чират булганда – 15 минуттан да артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 30 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә | Рөхсәт бирү тәртибенең 13 пункты |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Инвалидларга муниципаль хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем ала алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем ала алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозу прецедентлары (нигезле шикаятьләр) булу.<br>Муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә күрсәткәндә (алга таба – КФҮ) консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасының Бердәм | Рөхсәт бирү тәртибенең 11 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алырга мөмкин. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон рәвештә бирү законда каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча процедуралар (гамәлләр) эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Гариза бирүче, муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турындагы консультацияләрне телефон һәм (яки) электрон почта аша алу өчен, Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә документлар тапшыра (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе).

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза электрон почта яки Интернет-кабул итү аша эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән гариза.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге куеп, тапшырылган документлар исемлегенең күчермәсен бирә;

гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризаларны кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне язмача аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә;

гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә;

гариза һәм документларны гариза бирүчененең кулына кире кайтарып бирү – гариза бирүче шәхсән үзе булган вакытта 15 минут эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза һәм документлар, яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә һәм гариза һәм документларны карап тикшерү өчен Идарә башлыгына җибәрә (алга таба – идарә башлыгы).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Идарә башлыгы гариза һәм документларны карый, үтәүчене билгели (алга таба – Идарә белгече) һәм гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.4.1. Идарә белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны (мәгълүматларны) тапшыру турында запросны (алга таба – ведомствоара запрослар) мәгълүмат белән тәэмин итүчеләргә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Идарә белгеченә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүченең белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соралган документларны (мәгълүматларны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәр җибәрә (алга таба – документның (мәгълүматның) булмавы турында хәбәр итү).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче орган яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, башка норматив хокукый актлары нигезендә ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә документның (мәгълүматның) булмавы турындагы хәбәр.

3.5.Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1 Идарә белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) гаризага теркәлгән документлардагы мәгълүматларны тикшерә;

2) түбәндәге карар проектын әзерли:

- Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт проекты (алга таба – махсус рөхсәт);

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булганда);

3) карар проектын килешенү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенү өчен идарә башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.2. Идарә башлыгы кергән карар проектын карап тикшерә һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән, имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.3. Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый һәм аны теркәү өчен Идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган, Идарә белгеченә җибәрелгән карар проекты.

3.6. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен гариза бирүчегә бирү.

3.6.1. Идарә белгече имзаланган карар проектын теркәүне гамәлгә ашыра: махсус рөхсәтне – бирелгән махсус рөхсәтләрне теркәү журналында, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы хатны – махсус рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатларны теркәү журналында һәм гаризада күрсәтелгән телефон һәм (яки) электрон почта аша гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура имзаланган карар проекты Идарәгә кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6.2. Идарә белгече гариза бирүчегә махсус рөхсәтне, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы хатны бирә (яки почта аша җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче шәхсән үзе булган очракта – 15 минут эчендә;

җавап хат белән почта аша җибәрелгән очракта, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелген (җибәрелгән) махсус рөхсәт, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хат.

3.7. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә документлар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата табылган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 4 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә бирелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән техник хата булган документ;

3) техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе саналган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүченең (вәкаләтле вәкиленең) шәхсән үзе тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.8.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап шул көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Техник хатаны төзәтү турында гаризаны карап тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.4, 3.5 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Идарә белгече төзәтелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсен-документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхси имзасы белән гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алгач бирә яки гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) Идарәгә техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен-документны алу мөмкинлеге турындагы хатны җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе-документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары түбәндәгеләр:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килешенү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруны билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүен контроль тикшерүләрне билгеләнгән тәртиптә үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыруга җаваплы идарә башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы Башкарма комитет вазыйфаи затларының исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезнамәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренең үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

Идарә башлыгы әлеге Регламентның 3 нче бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларның үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү тәртибе

5.1. Гариза бирүче Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган

оешмаларның карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә), яки шул исәптән аларның хезмәткәрләренә түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны, комплекслы запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документларны тапшыруны яки гамәлләрне тормышка ашыру турындагы мәгълүматны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән кимчелекләр һәм хаталарны төзәтүне кире кагу яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең

1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең (алга таба – КФҮне оештыручы) тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга бирелә.

Башкарма комитет Җитәкчесенең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять Яр Чаллы шәһәре Шәһәр Советына бирелә.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять әлеге КФҮ җитәкчеләренә бирелә.

КФҮ карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять КФҮне оештыручыга яки Татарстан Республикасының норматив хокукый акты нигезендә вәкаләтле булган вазыйфаи затка бирелә.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет»ның мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.4. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көнендә.

Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта, яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон төрдә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында, Башкарма комитет, КФҮ яисә 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү формасы

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә

МАХСУС РӨХСӘТ № _____

(алгы як)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Йөк ташуның төре (регионара, җирле) | | Ел | |
| Үтәргә рөхсәт бирелгән | Бару вакыты | | кадәр |
| Маршруты | | | |
| | | | |
| Транспорт чарасы (автопоезд) (транспорт чарасының маркасы һәм моделе (тягачы, прицепы (ярымприцепы), транспорт чарасының дәүләт теркәве билгесе (тягачы, прицепы (ярымприцепы) | | | |
| | | | |
| Транспорт чарасының исеме, хуҗасының адресы һәм телефоны | | | |
| | | | |
| Йөкнең характеристикасы (исеме, габаритлары, массасы) | | | |
| | | | |
| Транспорт чарасының (автопоездның) параметрлары | | | |
| Транспорт чарасының (автопоездның) массасы, йөксез/йөк белән (т) | | Тягачның массасы (т) | Прицепның (ярымприцепның) массасы (т) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Күчәрләр арасындагы ара | | | |
| Күчәрләргә төшкән авырлык (т) | | | |
| Транспорт чарасының (автопоездның) габаритлары | Озынлыгы (м) | Киңлеге (м) | Биеклеге (м) |
| | | | |
| Рөхсәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән | | | |
| | | | |
| | | | |
| (вазыйфа) | (имза) | | (Ф.И.А.и.) |
| «__» ___________ 20__ ел | | | |

(арткы як)

| | |
|---|---|
| Озата бару төре | |
| Хәрәкәтнең аерым шартлары | |
| | |
| Йөк ташу килешенгән автомобиль юллары, корылмалар, инженерлык коммуникацияләре, Дәүләт автоинспекциясе идарәсе органнары һәм башка оешмалар (килешенгән оешманың исеме, килешенүнең номеры һәм датасы күрсәтелә) | |
| | |
| А. Россия Федерациясе юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташу өлкәсендәге норматив таләпләр һәм әлеге махсус рөхсәт белән таныштым | |
| Транспорт чарасын йөртүче (ләр) | |
| | (Ф.И.А.и.) имза |

| | |
|---|---|
| Б. Транспорт чарасы йөк белән/йөксез авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташу өлкәсендә әлеге махсус рөхсәттә күрсәтелгән норматив таләпләргә һәм параметрларга туры килә | |
| | |
| Транспорт чарасы хуҗасының имзасы | (Ф.И.А.и.) |
| «__» ___________ 20__ ел | М.У. (булганда) |
| Транспорт чарасы хуҗасының юл йөрү (юл йөрүләр) турында куйган билгеләре (һәр юл йөрүнең башлану датасы һәм вакыты күрсәтелә, оешманың җаваплы затының имзасы һәм мөһере белән раслана (булганда) | |
| | |
| | |
| Регионара һәм җирле йөкләр ташыганда йөк төяп җибәрүченең йөк төяп җибәрү турында куелган билгеләре (йөк төяүнең датасы һәм вакыты, йөк төяп җибәрүченең реквизитлары күрсәтелә, оешманың җаваплы затының имзасы һәм мөһере белән раслана (булганда) | |
| | |
| | |
| (билгеләр куелмаганда гамәлдә түгел) | |
| Контрольдә тотучы органнар куйган билгеләр (датасы һәм вакыты күрсәтелә) | |
| | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Гариза формасы

Башкарма комитет Җитәкчесе
____________________________________
(Ф.И.А.и.)
____________________________________
(кемнән: Ф.И.А.и./юридик затның исеме,
____________________________________
яшәү урыны адресы /юридик затның урнашкан урыны,
____________________________________
элемтә телефоны)

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә

## ГАРИЗА

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Транспорт чарасының исеме, хуҗасының адресы һәм телефоны | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| Транспорт чарасының ИНН, ОГРН/ОГРИП | | | | |
| Хәрәкәт маршруты | | | | |
| | | | | |
| Йөк ташуның төре (регионара, җирле) | | | | |
| Срогы | | | кадәр | |

<table>
<tr><td>Юлда йөрүләр саны</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Йөкнең характеристикасы:</td><td>Бүленә торган</td><td>әйе</td><td>юк</td></tr>
<tr><td colspan="2">Исеме[1]</td><td>Габаритлары</td><td>Массасы</td></tr>
<tr><td colspan="2"></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="4">Транспорт чарасы (автопоезд) (транспорт чарасының маркасы һәм моделе (тягачы), транспорт чарасының дәүләт теркәү номеры (тягачы, прицепы (ярымприцепы)</td></tr>
<tr><td colspan="4"></td></tr>
<tr><td colspan="4">Транспорт чарасының (автопоездның) параметрлары</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Транспорт чарасының (автопоездның) массасы, йөксез/йөк белән (т)</td><td rowspan="2"></td><td>Тягачның массасы (т)</td><td>Прицепның (ярым-прицепның) массасы) (т)</td></tr>
<tr><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Күчәрләр арасындагы ара</td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Күчәргә төшкән авырлык (т)</td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="4">Транспорт чарасының (автопоездның) габаритлары</td></tr>
<tr><td>Озынлыгы (м)</td><td>Киңлеге (м)</td><td>Биеклеге (м)</td><td>Йөк белән борылуның минималь радиусы (м)</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Озата баручы (саклап баручы) автомобильнең кирәклеге</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="3">Транспорт чарасының (автопоездның) күздә тоткан максималь хәрәкәт тизлеге (км/сәг.)</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Банк реквизитлары</td><td></td></tr>
</table>

---

[1]Графада йөкнең тулы исеме, төп характеристикалары, маркасы, моделе, индивидуаль һәм транспорт тарасына тасвирлама (беркетү алымы) күрсәтелә.

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| Түләүне гарантиялибез | | |
| | | |
| (вазыйфа) | ______________________<br>(имза) | ______________________<br>(имзаның расшифровкасы) |

«___» _________ 20___ел

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ПРОЦЕДУРАЛАР (ГАМӘЛЛӘР) ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ




Идарә башлыгы тарафыннан гаризаны карап тикшерү, аны үтәүчегә - идарә белгеченә җибәрү
Идарә белгеченә җибәрелгән гариза
Идарә белгече тарафыннан гаризаны карап тикшерү, ведомствоара запрослар әзерләү һәм аларны мәгълүмат куючыларга җибәрү
Җибәрелгән ведомствоара запрослар
Ведомствоара запросларга җаваплар алу һәм карар проектлары әзерләү (махсус рөхсәт бирү яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат) һәм аны килешенү өчен идарә башлыгына җибәрү
Идарә башлыгына җибәрелгән карар проекты
Идарә башлыгы тарафыннан карар проектын килешенү һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрү
Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты
Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карар проектын имзалау һәм аны теркәү өчен идарә белгеченә җибәрү
Теркәү өчен җибәрелгән карар проекты
Идарә белгече тарафыннан карар проектын теркәү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең әзерлеге турында хәбәр итү
Гариза бирүчегә хәбәр итү
Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә бирү яки җибәрү
Гариза бирүчегә бирелгән яки җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

## Техник хатаны төзәтү турында гариза формасы

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесе
__________________________________________
(Ф.И.А.и.)

________________________________________
__________________________________________
__________________________________________
__________________________________________

(физик зат өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), гариза бирүченең яшәү урыны, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары; юридик зат өчен: исеме, юридик затның бердәм дәүләт юридик затлар реестрында теркәлүе турында дәүләт теркәлүе язуының номеры, салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче (чит илнең юридик заты булу очрагыннан тыш; гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы)

### Техник хатаны төзәтү турында
### ГАРИЗА

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм _________
____________________________________________________________________________
(муниципаль хезмәтнең исеме)

Язылган: ____________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: _________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе саналган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:
E-mail: ___________________адресына электрон документ җибәрү юлы белән;
расланган күчермәне кәгаздә почта аша түбәндәге адрес буенча:
____________________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә үземнең ризалыгымны һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затның ризалыгын раслыйм (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), блокировкалау, персональ мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка эш итүләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатында муниципаль хезмәт күрсәтүченең шулар нигезендә карар кабул итүен дә кертеп.

Гаризага кертелгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка караган мәгълүматлар, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза бирү моментына әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда түбәндәге телефон аша катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________.

| | | |
|---|---|---|
| ___________________________ | ___________________________ | ___________________________ |
| (гариза бирүче юридик затның вазыйфасы) | (имза) | (Ф.И.А.и.- имзаның расшифровкасы) |

М.У.

«____» _________ 20__ ел

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Kancel.chelny@tatar.ru |
| Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | 30-55-51 | Kancel.chelny@tatar.ru |
| Шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы | 30-55-57 | Ik414@mail.ru |
| Шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе юл хуҗалыгы бүлекчәсенең баш белгече | 30-57-95 | Ik414@mail.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ